**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет Карамалинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитеты**

ул. Центральная, д. 8, село Карамалы, Азнакаевского муниципального района, 423301
Тел. (факс) (8-292) 45-6-42

Үзәк урам, 8, Карамалы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423301
Тел. (факс) (8-292) 45-6-42

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» сентябрь 2017 ел № 15

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә 24.03.2004 N 23-ТРЗ "Җирле референдум турында", «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясында карар бирәм:

1. Мәсьәлә буенча җирле референдум уздыру инициативасы белән чыгарга:

"Сез 2018 елда Карамалы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр куюны, кече архитектура формаларын урнаштыруны һәм карап тотуны кертеп);

3) ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карар:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы авылы, Совет ур., 49нчы йорт; ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы авылы, Яшьләр ур., юл чатында 20нче йорт, ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы авылы, Яшьләр ур., 46 нчы һәм 37 нче йортлар арасында; ТР, Азнакай муниципаль районы, Октябрь-Бүләк авылы, Үзәк урам, мәчет каршында; ТР, Азнакай муниципаль районы, Таллы Бүләк авылы, Үзәк урам, авыл мәдәният йорты каршында.

- Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru,

- «Интернет " мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык Ногманов А.Р.